# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2022 елның 29 нче марты №75

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

1) милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль программаларны (подпрограммаларны) формалаштыру һәм гамәлгә ашыру;

2) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләрен анализлау һәм аны үстерү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү фаразлары буенча чараларны куллануның нәтиҗәлелеген анализлау;

3) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар һәм әлеге оешмаларның структур бүлекчәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

5) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органнарын төзү.

2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Олы Ачасыр авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә башкарыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**